**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы
авылы, Татарстан урамы, 17 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

---

**2021елның 20 октябре** **70 номер**

# КАРАР

## Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Салым ставкаларының түбәндәге күләмнәрен билгеләргә:

1.1 Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;
1.2 Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) торак төзелеше өчен сатып алынган ) җир кишәрлекләренә карата- 0,3 %
1.3 Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата "Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата- 0,3 %;
1.4 Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;
1.5 1,5 % башка җир кишәрлекләренә карата.

2. Түбәндәге салым ташламаларын бирергә:
2.1 Түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымыннан азат итәргә:
а) граждан күмү белән мәшгуль оешмалар һәм учреждениеләр җир кишәрлекләренә карата;

б) муниципаль казна учреждениеләре - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, күп катлы һәм азкатлы торак төзелеше, рекреацион билгеләнештәге һәм ял итү, Физик культура һәм спорт билгеләнешендәге җирләргә карата , янгын деполары, су башнялары, скважиналар, су алу корылмалары, су фонды объектлары, канализация-насос станцияләре, чистарту корылмалары, каты көнкүреш калдыклары чүплекләре, үләт базлары, социаль һәм коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары, мунчалар, скверлар, парклар, мәйданнар, шәһәр бакчалары, һәйкәлләр, обелисклар, урамнар, автомобиль юллары белән, чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксызкуллана торган башка гомуми файдаланудагы объектлар, мәдәни үсеш объектлары белән тәэмин ителгән җир кишәрлекләренә карата;
в) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, шулай ук Әфганстанда сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;
г) "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында" Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә) нигезендә, "Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия булган физик затлар,"1957 елда "Маяк" җитештерү берләшмәсендә авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия булган физик затлар;
д) балачактан инвалидлар, инвалид балалар;
е) янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары.

Физик затларга ташламалар, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган, салым түләүченең теләге буенча, бер җир участогына карата бирелә дип билгеләргә.
Физик затның салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым түләүче тарафыннан салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.
2.2 салым ставкаларының түбәндәге күләмнәрен билгеләргә:
а) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының берләштерелгән бюджетыннан финанслана торган казна, бюджет һәм автоном учреждениеләргә, дәүләт хакимияте һәм идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына караган җир кишәрлекләренә карата 0,035 %;
б) эксплуатациясе коммерция нигезендә гамәлгә ашырыла торган гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 %;
в) «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001 %.

3. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы таныла дип билгеләргә.

4. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше процент ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел. Әлеге карар үз көченә кергән көннән «Җир салымы турында» 2015 елның 9 октябрендәге 8 номерлы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карары (26.06.2017 №66, 30.10.2017 №83, 18.10.2018 №111, 17.12.2018 №123, 17.10.2019 №153, 24.08.2021 №62 карарларындагы үзгәрешләре белән) үз көчен югалта.

6. Әлеге карарны Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда htth://pravo.tatarstan.ru веб адресы буенча , Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге, Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында htth://laishevo.tatarstan.ru веб адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советының Икътисадый үсеш һәм план-бюджет комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Ф. Мөбәрәкшин**